МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.03.2015 Казан ш. № 108

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында**

«Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы рәвештә **боерам:**

1. Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында (алга таба – Министрлык) вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Министрлыкта Исемлеккә кергән вазыйфаны биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә «Коррупциягә каршы тору турында»

2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы түбәндәгеләрне аңлатырга:

әгәр әлеге оешма белән дәүләт (административ) идарә итүенең аерым функцияләре Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең вазыйфаи (хезмәт) йөкләмәләренә кергән булса, Министрлыкта Исемлеккә кергән вазыйфаны биләгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң, Министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайлау комиссиясе рөхсәте белән, ике ел дәвамында хезмәт килешүе шартларында вазыйфалар били һәм (яки) граждан-хокукый килешүе (граждан-хокукый килешүләре) шартларында бер ай дәвамында әлеге оешмада бәясе йөз мең сумнан арткан эшләр эшли (хезмәтләр күрсәтә) ала;

Министрлыкта Исемлеккә кергән вазыйфаны биләгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң, ике ел дәвамында әлеге пунктның икенче абзацындагы күрсәтелгән эшләр эшләү (хезмәтләр күрсәтү) турында хезмәт яки граждан-хокукый килешүләре төзегәндә эш бирүче вәкиленә үзенең соңгы хезмәт урыны турында мәгълүмат бирүе мәҗбүри;

Министрлыкта Исемлеккә кергән вазыйфаны биләгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң, әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән таләпләрнең үтәлмәве, гражданин белән әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) үтәү буенча төзелгән хезмәт яки граждан-хокукый килешүләрнең өзелүенә китерә.

3. Министрлыкның «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфага билгеләнгәндә гражданнар өчен үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган һәм

шулай ук вазыйфаны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2014 елның 11 ноябрендәге 413нче боерыгы үз көчен югалта дип танырга.

4. Кадрлар бүлегенә:

Исемлеккә кергән дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга;

әлеге боерыкның билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвен узуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**Министр** **А.А.Здунов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
боерыгы белән расланган
5 март 2015 ел № 108

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары;
2. Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары;
3. Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары – Эшкуарлыкны үстерү департаменты башлыгы;
4. Эшләр белән идарә итүче;
5. Министр ярдәмчесе;
6. Фаразлау һәм стратегик үсеш идарәсе башлыгы;
7. Административ реформа мәсьәләләре идарәсе башлыгы;
8. Территориаль үсеш идарәсе башлыгы;
9. Инвестицияле һәм инновацияле эшчәнлек идарәсе башлыгы;
10. Оештыру идарәсе башлыгы;
11. Юридик бүлек башлыгы;
12. Финанс исәбе һәм хисап бүлеге башлыгы;
13. Кадрлар бүлеге башлыгы;
14. Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара эш итү бүлеге башлыгы;
15. Режим, мобилизацион әзерлек, гражданлык оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр секторы мөдире;
16. Юридик бүлек башлыгы урынбасары;
17. Финанс исәбе һәм хисап бүлеге башлыгы урынбасары;
18. Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара эш итү бүлеге башлыгы урынбасары;
19. Эшкуарлыкны үстерү департаменты башлыгы урынбасары;
20. Икътисад һәм социаль өлкә тармаклары үсеше башлыгы;
21. Инвестицияле эшчәнлек бүлеге башлыгы;
22. Инвестицияле проектларга дәүләт ярдәме күрсәтү бүлеге башлыгы;
23. Инновацияле эшчәнлек бүлеге башлыгы;
24. Конкуренцияне үстерү бүлеге башлыгы;
25. Муниципаль берәмлекләрне үстерү бүлеге башлыгы;

26. Максатчан программалар бүлеге башлыгы;
27. Лицензияләү бүлеге башлыгы;
28. Икътисадый анализ һәм финанс продуктлары бүлеге башлыгы;
29. Кече һәм урта эшкуарлык инфраструктурасын үстерү бүлеге башлыгы;
30. Финанс-хокукый консультацияләр бүлеге башлыгы;
31. Мәгълүматлаштыру бүлеге башлыгы;
32. Административ-хуҗалык бүлеге башлыгы;
33. Җайлау йогынтысын бәяләү һәм икътисад өчен кадрлар әзерләү секторы мөдире;
34. Инновацияле эшчәнлек бүлеге башлыгы урынбасары;
35. Муниципаль берәмлекләрне үстерү бүлеге башлыгы урынбасары;
36. Максатчан программалар бүлеге башлыгы урынбасары;
37. Инвестицияле проектларга дәүләт ярдәме күрсәтү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;
38. Инвестицияле проектларга дәүләт ярдәме күрсәтү бүлегенең әйдәп баручы консультанты;
39. Конкуренцияне үстерү бүлегенең әйдәп баручы консультанты;
40. Конкуренцияне үстерү бүлегенең әйдәп баручы белгече;
41. Лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;
42. Лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы консультанты;
43. Икътисадый анализ һәм финанс продуктлары бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;
44. Икътисадый анализ һәм финанс продуктлары бүлегенең әйдәп баручы белгече;
45. Кече һәм урта эшкуарлык инфраструктурасын үстерү бүлегенең әйдәп баручы белгече;
46. Кече һәм урта эшкуарлык инфраструктурасын үстерү бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;
47. Финанс-хокукый консультацияләр бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;
48. Финанс-хокукый консультацияләр бүлегенең әйдәп баручы консультанты.